ПӘНҖЕШӘМБЕ
18
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 40 (6762)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Безнең гаскәрләр Славянск, Ровеньки, Свердловск, Богодухов, Змиев, Грайворон шәһәрләрен алдылар

1) 17 нче февральдә Украинада безнең гаскәрләр, каты сугышлар нәтиҗәсендә, СЛАВЯНСК шәһәрен һәм тимер юл узелын, шулай ук РОВЕНЬКИ, СВЕРДЛОВСК, БОГОДУХОВ, ЗМИЕВ шәһәрләрен алдылар.

2) Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, ГРАЙВОРОН шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ

ЯҢА ГҮЗӘЛ ҖИҢҮ

Бөек полководец иптәш Сталин җитәкчелегендәге данлыклы Кызыл Армия көнбатышка таба уңышлы һөҗүм белән алга баруны дәвам иттерә. Гитлерчы армияләргә яңадан-яңа җимергеч ударлар ясала. Генерал-полковник иптәш Р. Я. Малиновский командалыгындагы Көньяк фронт гаскәрләре 14 нче февральдә, дошманның ныклы каршылык күрсәтүен җиңеп, Ростов-Дон шәһәрен алдылар. Армия генералы иптәш Н. Ф. Ватутин командалыгындагы Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре, бик каты сугышлар нәтиҗәсендә, Ворошиловград (Украина), Красный Сулин (Ростов өлкәсе) шәһәрләрен алдылар.

Кичәге көн тагын да шатлыклы хәбәр китерде. Генерал-полковник иптәш Ф. И. Голиков командалыгындагы гаскәрләр группасы Украинаның иң зур шәһәрләреннән берсе булган Харьков шәһәрен алды. Харьков районында немец-фашист басып алучыларга тагын бер җимергеч удар ясалды. Монда немецларның, ничек кенә итеп булса да Харьковны үз кулларында саклап калырга приказ алган гарнизоны—башкисәрләр корпусы һәм башка сайланма гаскәрләр тар-мар ителде.

Ростов-Дон, Ворошиловград, Красный Сулин, Харьков яңадан безнеке! Совет халкының азатлыгы, бердәмлеге һәм куәте символы булып бу шәһәрләрдә яңадан кызыл байраклар җилферди!

Кызыл Армия яңадан-яңа гүзәл җиңүләр яулап ала. Аның куәтле ударлары астында мактанчык немец армияләре көнбатышка тәгәриләр. Совет гаскәрләренең бу героик көрәшен бөтен алдынгы кешелек дөньясы тирәнтен соклану белән күзәтә. Ә совет халкы фронтта җиңүләр турындагы һәрбер яңа хәбәрне шатлык һәм тирән дулкынлану белән каршы ала. Фронтовикларның бу җиңүләренә безнең тылыбыз яңа патриотик күтәренкелек һәм фронтка ярдәмне көчәйтү белән җавап бирә.

Бу көннәрдә республикабызның предприятиеләрендә, колхозларында һәм совхозларында күп кешеле митинглар булып тора. Совет кешеләре фронтлардагы җиңүләр уңае белән үзләрендә туган патриотик хисләрне һәм шатлыкны уртаклашу өчен митингларга, җыелышларга киләләр. Патриотларның ялкынлы речьләре ватан өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшергә әзер торулары турында тантаналы ант булып яңгырый. Бу ант конкрет эш белән беркетелә. Социалистик ярыш йөкләмәләрен срогыннан элек үтәү һәм арттырып үтәү өчен көрәш тагын да көчлерәк һәм кызурак темп ала.

Кызыл Армиянең данлыклы 25 еллыгы якынлаша. Фронт сугышчылары бу көнне яңадан-яңа җиңүләр белән, дистәләрчә шәһәрләрне, йөзләрчә авылларны һәм меңнәрчә совет кешеләрен немец-фашист басып алучылар коллыгыннан азат итү белән каршылыйлар. Хезмәт фронты сугышчылары! Ватан алдындагы бурычыбызны намус белән үтик! Бу тарихи датаны—Кызыл Армиянең 25 еллыгын—производствода яңа җиңүләр яулап алу белән, язгы чәчүгә отлично әзерләнү, фронтка кирәкле продукцияне тагын да күбрәк җитештерү белән каршы алыйк. һөҗүм итүче фронтовикларга ярдәмне көчәйтик! Дошманны тәмам тар-мар итү сәгатен якынайтыйк!

МОСКВА, КРЕМЛЬ

СССР Совнаркомы председателе Иосиф Виссарионович Сталинга

ДЭСНА электр станциясе эшчеләре, хезмәткәрләре һәм инженер-техник работниклары, фронтка ярдәмне тагын да көчәйтү теләге белән, үзләренең хезмәт хакларының бер өлешен һәм саклык акчаларын бирделәр. Станциянең коллективы, митингка җыелып, түбәндәгечә карар чыгарды:

1) Станциянең экономия белән һәм авариясез эшләвен тәэмин итәргә, Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең 25 еллыгына 160 тонна ягулыкка, 20.000 кловатт электр энергиясенә экономия ясарга, электр энергиясе эшләп чыгару буенча 2 айлык планны үтәргә.

2) «Советская гавань» исемле бомбардировщиклар эскадрильясы төзүгә инде 88.000 сум акча җыелды һәм тапшырылды; хәзер өстәмә рәвештә акча җыю башланып китте.

3) Хәрби заем буенча взнослар түләнеп бетеү уңае белән СССР хөкүмәтеннән «Немец оккупантларны тәмам тар-мар итү» исемле яңа заем чыгаруны үтенергә.

Безнең дәүләткә бурычка биреп торган акчаларыбыз һәм тапшырыла торган саклык акчаларыбыз немец оккупантларына каршы үлем коралы булып әверелсеннәр һәм гүзәл ватаныбызны тәмам азат итүне якынайтсыннар.

Митингның тапшыруы буенча кул куйдылар:

Федоров, Саркисов, Иртегова, Белый, Кравцов, Краснов, Захаров, Бобрицкий, Смелик, Кузнецов, Аккуратов, Киселев, Гарченков.

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ IX НЧЫ ПЛЕНУМЫ

13—16 нчы февральдә ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитетының IX нчы пленумы булып үтте. Пленумда ВКП(б) райкомнарының секретарьлары, хезмәт ияләре депутатларының район советлары башкарма комитетларының председательләре, МТС һәм совхоз политбүлекләренең начальниклары катнашты.

Пленум түбәндәге мәсьәләләрне тикшерде:

1. 1942 нче авыл хуҗалыгы елының йомгаклары һәм 1943 нче елгы язгы чәчү кампаниясенең бурычлары турында (ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **А. Г. Колыбанов** доклады).

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнаштылар: райком секретарьлары Басыйров (Чүпрәле), Баһаутдинов (Бондюг), Әхтәмов (Буа), Ямков, (Октябрь районы), мөбарәкҗанов (Тәтеш), Әминев (Мөслим), Гәрәев (Ворошилов районы), политбүлек начальниклары Хәйбуллин (Саба МТС ы), Зайцев; (Зур Поляна МТС ы), Ульянин («Татарстан» совхозы), Васильева (Чистай совхозы), Баһаутдинов («Росткаучук конторасы), ВКП(б) Өлкә Комитетының совхозлар бүлеге мөдире Әхмеров, Госплан председателе Цибин, ВКП(б) Өлкә Комитетының кадрлар буенча секретаре Долотказин, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Динмөхәмәтов, ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире Перов, Ионов (Заготзерно конторасы), ТАССР Совнаркомы председателе урынбасары Шәрәфиев, Сөт-ит совхозлары трестының политик секторы начальнигы Раздобудько, ТАССР Җир эшләре халык комиссары Хөсәенов, Татнаркомземның политсектор начальнигы Гончаров, ВЛКСМ Өлкә Комитеты секретаре Шәфиков, Фәннәр Академиясеннән Окунева һәм Лупинович иптәшләр.

2. Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында терлекчелекне үстерү буенча дәүләт планын үтәү йомгаклары турында. (ТАССР Совнаркомы председателе иптәш **С. Х. Гафиятуллин** доклады).

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнаштылар: райком секретарьлары Иванов (Тельман районы), Мингалиев (Әгерҗе), Давыдов (Яңа Чишмә), Матвеев (Чистай), Глухов (Алексеевск) Әбләлимов (Красный бор), Москвин (Питрәч), Садыйков (Олы Тархан), райисполком председательләре Мөхәметшин (Минзәлә), Молодцов (Лаеш), ит һәм сөт промышленносте халык комиссары Черзор, Ветинститут директоры Мухин, ТАССР поркуроры Ардрехин, Статистика идарәсе начальнигы Зайцев, Уполнаркомзаг Никишкин, Нырты совхозының политбүлек начальнигы Мясоутов, ВКП(б) Өлкә Комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире урынбасары Сергеев, Совнарком председателе урынбасары Шибдин һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре Бәдретдинов иптәшләр.

3. Татарстан партия оешмасы сафларының үсеше турында (ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Х. М. Пазиков** доклады).

Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда түбәндәге иптәшләр катнаштылар: райком сектарьлары Мексина (Молотов районы), Хакимҗанов (Минзәлә), Гриньков (Ленин районы), Хәйруллин (Апас), Щербинин (Чаллы), Денисов (Кукмара), ВКП(б)ның Зеленодольск шәһәр комитеты секретаре Дельвин, ВКП(б) Өлкә Комитетының пропоганда буенча секретаре Гафаров, ВКП(б)ның Казан шәһәр комитеты секретаре Барышников, Макыл МТС ының политбүлек начальнигы Михайлов, Эчке Эшләр халык комиссары Габитов, «Красная Татария» газетасы редакторы Анушкин, ВКП(б) Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире Арнаутов иптәшләр.

Барлык докладлар буенча тиешле карарлар кабул ителде.

Пленум шулай ук оештыру мәсьәләләрен тикшерде. Пленум иптәш **Х. М. Пазиковны** ВКП(б) Өлкә Комитетының икенче секретаре итеп сайлады, аны ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы составына кертте һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы члены итеп сайлады. Промышленность тармаклары буенча ВКП(б) Өлкә Комитеты секретарьларыннан иптәш **А. А. Абецедарский** һәм иптәш **Г. Г. Измайлова** ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы члелыгына кандидат итеп сайландылар.

Пленум, иптәш **Г. Г. Измайлованы** гомуми промышленность буенча, иптәш **Н. И. Дмитриевны** җиңел һәм җирле промышленность буенча, иптәш **А. А. Эмин**[illegible] электр станцияләре буенча, иптәш **Е. Р. Федоровны** җирле ягулык промышленносте буенча ВКП(б) Өлкә Комитетының секретарьлары итеп сайлады.

* * *

Пленум тәмам булганнан соң андагы барлык катнашучылар өчен Авыл хуҗалыгы институты доценты, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты иптәш Вершинин академик Т. Д. Лысенконың агротехник күрсәтмәләрен тормышка үткәрү турында һәм Авыл хуҗалыгы институты доценты, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты иптәш Коньков терлекләрне рационал ашату турында лекцияләр укыдылар.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ
ИПТӘШ АЛЕКСЕЙ ЕГОРОВИЧ БАДАЕВНЫ ЛЕНИН ОРДЕНЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Иптәш А. Е. Бадаевка 60 яшь тулу уңае белән һәм аның совет халкы алдындагы хезмәтләрен искә алып иптәш Алексей Егорович **Бадаевны** Ленин **ордены** белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе
М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
16 февраль, 1943 ел.



ТӨНЬЯК ФЛОТ. Рәсемдә: техниклар самолетларны сугышчан очышка әзерлиләр, аларга бомбалар, торпедалар, миналар тагалар.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

17 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

17 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр тар-мар ителгән немец-фашист гаскәрләренең калдыкларын куып бардылар. Харьковта кулга төшерелгән доументлар арасында немецлар командованиесенең Харьков гарнизоныннан шәһәрне ничек кенә итеп булса да саклап калуны таләп итә торган приказлары табылды. Немецлар, төп удар көнчыгыштан ясалыр дип уйлаган булганнар һәм шунда бик күп мотопехота һәм танклар туплаганнар. Дошман өчен һич тә көтелмәгәндә совет гаскәрләре ударны төньяктан ясадылар һәм шәһәр читләренә бәреп керделәр. Шул ук вакытта безнең частьлар башка участокларда да дошманның оборонасын җимерделәр һәм бик каты урам сугышларыннан соң Харьков яңадан совет шәһәре булып калды. Харьков районында дошманның бик күп җанлы көчләре һәм техникасы юк ителде. Төрле әйберләр тутырылган күп складлар, кораллар һәм транспорт средстволары кулга төшерелде. Аларның исәбе алына.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман каты каршылык күрсәтә, ләкин совет частьларының ударлары астында, авыр югалтуларга дучар булып, халык яши торган пунктларны бер-бер артлы калдыра. Халык яши торган бер пункт урамнарында гына да гитлерчыларның 200 гә якын үле гәүдәләре табылды. 2 самоход орудие, 11 пулемет, 3 миномет һәм бер сугыш припаслары складлары кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең танкистлар немецларның 3 танкысын сафтан чыгардылар, зур пехота колоннасын таркаттылар һәм шактый өлешен кырып бетерделәр.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Гитлерчылар безнең частьларның алга баруын ничек кенә булса да тоткарларга маташалар. Н-че часть сугышчылары дошманның контратакасын кире кайтардылар һәм 400 гә якын гитлерчыны кырып ташладылар. Немецларның 6 танкысы сафтан чыгарылды. Икенче бер участокта безнең моторлаштырылган частебыз дошманның бер рота пехотасын тар-мар итте, 4 танкысын һәм йөк төялгән 15 автомашинасын юк итте.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары немецларның каршылык күрсәтүен бастырып, алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Халык яши торган бер зур пунктта безнең сугышчылар немецларның плен бирелүдән баш тарткан гарнизонын чолгап алдылар һәм юк иттеләр. 600 дән артык гитлерчы кырылды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Волхов фронтында һава сугышларында, зенит артиллериясенең һәм коры җир гаскәрләренең уты белән бер көн эчендә немецларның 14 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Смоленск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары немец басып алучыларга каршы сугышларда 106 дошман солдатын һәм офицерын кырганнар. Смоленск партизаннарының икенче бер отряды бер ай эчендә немецларның сугыш техникасы һәм гаскәр төялгән 8 хәрби эшелонын юлдан чыгарган.

* * *

Курск өлкәсенең Гнилое авылында немец-фашист кабахәтләр 180 кешене атып үтергәннәр. Палачлар тоташ семьяларны суйганнар. 11 кешедән торган Гусаихиннар семьясы, 5 кешедән торган Поповлар семьясы, 4 кешедән торган Бобровскийлар семьясы, 4 кешедән торган Сычевлар семьясы һәм башкалар ерткыч төстә үтерелгәннәр.

СССР Верховный Советы Президиумы УКАЗЫ

АРМИЯ ГЕНЕРАЛЫ А. М. ВАСИЛЬЕВСКИЙГА СОВЕТЛАР СОЮЗЫ МАРШАЛЫ ДИГӘН ХӘРБИ ИСЕМ БИРҮ ТУРЫНДА

Армия генералы Александр Михайлович Василевскийга Советлар Союзы Маршалы дигән хәрби исем бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе

М. КАЛИНИН.

СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре

А. ГОРКИН.

Москва, Кремль. 16 февраль, 1943 ел.

СОВЕТ ГАСКӘРЛӘРЕ ХАРЬКОВНЫ АЛДЫЛАР

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ, 16 февраль. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Соңыннан кан коюлы урам сугышларына әйләнгән кискен штурм нәтиҗәсендә, совет гаскәрләре Харьков шәһәрен алдылар. Кызыл Армия тагын бер гүзәл җиңүгә иреште. Харьков өчен булган сугышларда совет частьлары немецларның «Адольф Гитлер» һәм «Райх» исемле ике танк дивизиясеннән һәм «Бөек Германия» исемле мотодивизиядән торган «СС» корпусын, шулай ук немецларның күп кенә пехота дивизияләрен һәм махсус частьларын тар-мар иттеләр.

Фашистик командование Харьковны күп дистәләрчә километрга сузылган һәм көчле итеп ныгытылган чикләр белән саклап торды. Немецларның ныгытмалары шәһәрдән ерак урыннарда Оскол елгасына, ә шәһәргә якын урыннарда—Төньяк Донец елгасына барып терәлгән иде. Совет гаскәрләренең омтылышлы рәвештә алга баруларын тоткарларга маташып, дошман бу чикләргә үзенең частьларын туплады.

Гитлерчыларның планнары җимерелде. Совет танкистлары, артиллеристлары, пехотачылары һәм очучылары, фашистларны бертуктаусыз куа барып, аларга төп позицияләрдә дә, шулай ук аларның араларында да көчләрен яңадан оештырырга һәм ныгып калырга ирек бирмәделәр.

Сугышларның һәрбер көне немец-фашист частьларын торган саен хәлсезләндерә барды. Безнең гаскәрләрнең басымын тоткарларга теләп, немецлар командованиесе Харьков янына эсэсчылар корпусын китерде. Эсэсчыларның отрядлары танклар белән көчәйтелеп иң җаваплы участокларга куелдылар. Фашистлар бик каты каршылык күрсәттеләр, ләкин безнең гаскәрләрнең көчле һөҗүм ташкыны белән алып ташландылар.

«Дейчланд» исемле эсэсчылар полкының 1 нче батальоныннан плен алынган өлкән ефрейтор Роберт Графф түбәндәгеләрне белдерде: «Безнең рота беренче сугышларда ук үзенең личный составының өчтән бер өлешен югалтты. Безнең полкка бирелгән 60 танктан бары 20 генә танк калды. Зур югалтулар безне артка тәгәрәргә мәҗбүр иттеләр. Без шул кадәр ашыгыч чигендек ки, хәтта яралыларны да җыеп ала алмадык».

Безнең полкларның җимергеч ударлары астында эсэсчыларның башка частьлары да таркалдылар һәм тәртипсез рәвештә чигенә башладылар. Совет гаскәрләре шәһәрне ярым түгәрәк рәвешендә уратып алып кыса башладылар.

Харьковка! Бу сүзләр сугышчан чакыру булып яңгырадылар. Алар сугышчыларны һәм командирларны алга өндәделәр. Безнең частьлар үз юлларындагы бөтен тоткарлыкларны җимереп, Харьковка таба бардылар: Көнбатыштан һөҗүм итүче сугышчылар төнлә дә һәм көндез дә, карлы бураннарда да, кеше үтә алмаслык юлларда кан коюлы сугышлар алып барып, шәһәргә таба үттеләр. Алар, дошманга каршы бик каты сугышларда һәрбер метр җирне яулап алып, орудиеләрне үзләре тартып алып бардылар. Сугышчылар, немецлар тарафыннан яндырылган совет авылларын күрделәр, фашистлар коллыгына төшеп меңнәрчә рус кешеләре газап чиккән шәһәрләрне үттеләр.

Совет сугышчылары куркуны да, аруны да белмәделәр. Батарея командиры Коновалов, безнең пехотачылар сугыш алып бара торган бер авылга таба үзенең артиллеристлары белән барганда, дошманның зур бер группасына очрады. Артиллеристларны гитлерчылар чолгап алдылар. Алар җиңәргә өметләнделәр. Коновалов дошманга ут ачарга приказ бирде. Артиллеристлар, орудиеләргә атака ясаучы немецларга туп-туры аттылар һәм 300 гә якын фашистны кырдылар. Бик нык яраланган булуына карамастан, Коновалов: «Яшәсен Харьков!», дип кычкырды.

Бөек Украина шәһәренең стеналары янында Советлар Союзындагы барлык халыкларның вәкилләре сугыштылар. Татар егете Кураев һәм башкорт Исхаков икәүләп дистәләрчә немецларга каршы тигезсез сугышка керештеләр. Совет сугышчылары гранаталар ыргытып һәм автоматтан атып 10 гитлерчыны кырдылар һәм калганнарын таркаттылар. Азербайҗан егете Мамедов штык һәм приклад белән сугышып 12 немецны юк итте.

Безнең частьлар шәһәргә якынрак килгән саен немецлар шул кадәр ныграк каршылык күрсәттеләр. Фашистик командование үзенең тар-мар ителгән полкларының калдыкларын үлемгә ташлады. Гитлерчылар, үз кулларында булган бөтен нәрсәне файдаланырга тырыштылар. Сугыш кырында, хәтта, моңа кадәр Харьков урамнарында жандармлык хезмәте алып барган, полицейскийлар батальоны да күренде. Фашистлар бер-бер артлы контратакалар ясадылар. Гитлерчылар безнең гаскәрләрнең көнчыгышта алга баруларын туктатырга маташканнар иде, ләкин шул ук вакытта төньяктан һөҗүм итүче совет подразделениеләре шәһәргә якын ук килеп җиттеләр.

Кискен штурм моменты җилеп җитте. Генерал-майор Зайцев, полковник Костицын, генерал-майор Мартиросян частьлары төрле юнәлешләрдән Харьковка бәреп керделәр. Безнең частьлар шәһәрнең төньяк читеннән дошманның тылына удар ясадылар. Дошман үзенең бөтен игътибарын көнчыгыш якка туплаган иде, чөнки безнең башка частьларның сугышчылары дошман гарнизонына шул яктан штурм ясыйлар иде. Мартиросянның сугышчылары көчле омтылыш белән алга китеп үзенең биеклеге белән шәһәрдә хөкем сөрүче Холодная Гораны алдылар. Безнең подразделениеләр биеклектә тиз генә пулеметлар һәм минометлар урнаштырып, контратака ясау өчен окоплар казып урнашкан эсэсчыларның тауга якын урамнардагы һәм тимер юл полотносы буендагы позицияләренә ут ачтылар.

Шул ук вакытта шәһәрнең үзәк урамнарыннан берсенә бер группа автоматчиклар бәреп керделәр. Штык һәм кул сугышы башланып китте. Безнең сугышчылар гранаталар ыргытып эсэсчыларны йортлардан кысрыклап чыгардылар һәм штыклар белән чәнчеп үтерделәр. Урам сугышлары искиткеч көчле характер алды. Эсэсчылар һәрбер квартал, һәрбер йорт өчен котырынып сугыштылар. Мина кырларының күп булуы шәһәрдә безнең частьларның алга баруын акрынайтты. Күп кенә урыннарда аерым йортлар өчен генә түгел, хәтта баскыч клеткалары өчен дә, аерым бүлмәләр өчен дә бик каты штык сугышлары алып барылды.

Шәһәр банкысы бинасы янында бик көчле сугыш башланып китте. Безнең сугышчылар йорт алларында, подвалларда һәм өйләрнең чардакларында бик күп тапкырлар штык сугышлары алып барганнан соң Дзержинский мәйданын дошманнан чистарттылар. Немецлар көнбатышка таба тәгәри башладылар. Шул ук вакытта, дошман кулындагы бердән-бер коммуникация булган шоссе юлына безнең танкистлар бәреп чыктылар. Алар чигенеп баручы дошманны сыттылар һәм аны гаять зур югалтуларга дучар иттеләр. Безнең сугышчылар дошманның соңгы каршылык күрсәтү урыннарын бастырдылар. Корал ташламаганнарның барысы да юк ителде. Шәһәрнең чикләрендә һәм урамнарында фашист солдатларның һәм офицерларның бик күп сандагы үле гәүдәләре аунап ята. Урам чатларында, таш биналар янында дошманнан алынган орудиеләр, тягачлар, автомашиналар, танклар тора.

Немецлар тарафыннан теткәләнеп беткән шәһәр җиңү тантанасын бәйрәм итә. Йортларның өсләрендә яңадан кызыл байраклар җилферди. Харьков халкы үзләрен гитлерчылар коллыгыннан азат иткән сугышчыларны котлый.

Харьков яңадан совет шәһәре!

Г. КРЫЛОВ.

СУД КИЛӘ

Дөберди күк, дөберди җир, ява ут.
Киләдер төсле җирнең асты өскә.
Ниһаять, әверелеп дәһшәтле көчкә,
Явызлардан алырга үч килә суд.
Котылмас бер фашист эт тә бу көнне
Иөрәктә чөнки үч чиктән ашылган.

Кем үтерелгән, суелган һәм асылган,—
Тынычлансын күреп мондый хөкемне.
Аяу күрсәтми дошманга җәзабыз,
Аяуны үзләре соң белделәрме?!
Манып дошман тәненә сөңгеләрне
Хөкемне кан белән җиргә язабыз.

Ә. ИСХАК.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (көнбатыш фронт). Рәсемдә: Азат ителгән пунктта шатлыклы очрашу.

ТАСС фотохроникасы.

Кызыл Армиягә— сугыш машиналары

САМОЛЕТЛАР ТӨЗҮ ФОНДЫНА

Актаныш районындагы «Кызыл көч» колхозы комсомолецлары һәм союздан яшь яшьләре «Татарстан комсомолы» исемле самолетлар эскадрильясы төзү фондына акча җыю эшен киң җәелдереп, бу гүзәл хәрәкәткә барлык колхозчыларны да тарттылар.

Комсомолецлардан Ә. Гаязов (оешма секретаре), Р. Имамова, Н. Хуҗина, Ә. Имамов һәм Ә. Борһанов иптәшләр, самолетлар эскадрильясы төзү фондына һәркайсы 10 ар мең сум акча кертеп, зур патриотлык үрнәге күрсәттеләр. Колхоз председателе иптәш Талипов 15.000 сум бирде һәм Кызыл Армия фондына бер сарык бүләк итте. «Кызыл көч» колхозы членнары бу фондка аз гына вакыт эчендә 500.000 сум акча туплап тапшырдылар. Бу сумманың 72.000 сумын колхозның комсомолецлары, 6.000 сумын пионерлар һәм укучылар җыйдылар.

Самолетлар эскадрильясына акча җыю һәм Кызыл Армия өчен бәйрәм бүләкләре әзерләү эше районның барлык колхозларында да зур күтәренкелек белән дәвам итә.

«Яңа тормыш» колхозы членнары самолетлар төзү фондына 350.000 сум акча керттеләр һәм Кызыл Армиягә бүләк фондына 27 баш сарык, бер бозау, 88 пот бәрәңге, 14 килограмм бал, май, оекбаш, бияләй һәм башка әйберләр тапшырдылар. Колхоз председателе иптәш Галиев әле күптән түгел генә «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына 8.500 сум акча һәм Кызыл Армия фондына 25 пот ашлык тапшырган иде. Ул самолетлар төзүгә тагын 15.000 сум акча бирде һәм бүләк фондына бер сарык тапшырды. Авыл советы председателе Г. Рәшитова, секретаре М. Тимершина иптәшләр 10 ар мең сум, ферма мөдире иптәш Гәрәев 20.000 сум, колхозчы М. Касимова 12.000 сум, Моңгыймә Касимова 15.000 сум, С. Тимергалин 20.000 сум бирделәр. Колхозчы иптәш Ялалов Кызыл Армиягә бүләк итеп 10 килограмм бал тапшырды.

«Ирек» колхозы бу фондка 150.000 сум акча тапшырды. «Актанышбаш» колхозы членнары 120.000 сум һәм Кызыл Армиягә бүләк фондына 19 баш сарык, 60 пот бәрәңге, 4 килограмм бал, 2 килограмм май, 8 килограмм йон, күп кенә сарык тиресе һәм башка әйберләр җыеп тапшырдылар.

Районда самолетлар эскадрильясы төзү фондына акча җыю һәм Кызыл Армия өчен бүләкләр әзерләү эше зур күтәренкелек белән дәвам итә.

З. ЗАКИРОВА.

* * *

Кукмара районы, Байлангор авылы колхозчылары самолетлар эскадрильясы төзү өчен средство җыюга актив катнашалар. Колхозчылардан Ә. Зарипова, Г. Баһаветдинов, Ш. Саттаров иптәшләр бу фондка берәр мең сум акча керттеләр. Колхоз барлыгы 60.000 сум акча җыеп тапшырды. «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына 90.000 сум акча тапшырылган иде.

Г. ГАЛИЕВА.

Ярдәмче хуҗалык—предприятиенең мөһим цехларыннан берсе

Н. ШИБДИН

ТАССР Совнаркомы председателе урынбасары

* * *

Бөек ватан сугышы көннәрендә совет патриотлары, дошманны мәрхәмәтсез кыручы, изге совет җирләрен немец-фашист кабахәтләрдән чистартучы батыр Кызыл Армиябез өчен кораллар, сугыш припаслары җитештерүдә үз-үзләрен аямыйча, армый-талмый эшлиләр. Совет, партия һәм профсоюз оешмаларының бурычлары—эшчеләргә, инженер-техник работникларга, мастерларга, хезмәткәрләргә, алар фронт өчен тагын да күбрәк көч биреп эшләсеннәр өчен, яхшы тормыш-көнкүреш шартлары тудырудан гыйбарәт. Аерым алганда, миллионнарча хезмәт ияләренең ихтыяҗларын үтәүче җәмәгать туклануы эшенә тагын да ныграк игътибар итәргә кирәк. Дәүләт тарафыннан җибәрелә торган продуктлар яхшы итеп, тәртипле рәвештә файдаланылырга һәм өстәмә азык ресурсларын булдыру юллары табылырга тиеш.

Предприятиеләр һәм учреждениеләр каршында төзелгән ярдәмче хуҗалыклар—хезмәт ияләренең туклануын җитди рәвештә яхшырту чыганаклары булып хезмәт итәргә тиешләр. Ярдәмче хуҗалыклар, алар—предприятиеләрнең мөһим цехлары.

Татарстанда хәзерге көндә 650 ярдәмче хуҗалык бар. Аларда узган елны 20.687 гектар җир чәчтеләр. Шулардан 1.005 гектарга яшелчә һәм 3.031 гектарга бәрәңге утыртылды. Ярдәмче хуҗалыкларда 48.000 рамнан торган парник һәм 3.547 квадрат метр теплица, 124 трактор, 2.847 ат, 5.913 баш эре мөгезле терлек, 10.683 баш дуңгыз, 1.561 баш сарык һәм кәҗә һ. б. бар. Димәк, эшчеләрне авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итүдә партия һәм хөкүмәт тарафыннан куелган бурычларны үтәүгә безнең ярдәмче хуҗалыкларыбызның бөтен мөмкинлекләре бар дигән сүз.

Үзләренең рольләрен һәм бурычларын аңлаган алдынгы хуҗалыклар эштә яхшы нәтиҗәләр бирүгә ирештеләр. Н-че завод, мәсәлән, узган елны һәрбер гектар яшелчәлек җирдән 125 центнер уңыш алды. Төзү тресты—119 центнер, завком председателе урынбасары Горовская булган завод 248 центнер, баш инженеры Корнеев булган завод үзенең шәһәр тәге ярдәмче хуҗалыгыннан 374 центнер алдылар һ. б. Мондый тырышып эшләүче ярдәмче хуҗалыклар үзләренең финанс хәлләрен дә шактый яхшырттылар һәм йөз мең сумнарча файда биреп эшлиләр.

Ләкин, кызганычка каршы, барлык ярдәмче хуҗалыклар да шулай яхшы эшлиләр дип әйтеп булмый әле. Төп җитешсезлек—уңышның түбән булуында. Эре 10 хуҗалык буенча бәрәңге уңышы уртача 44 центнердан, яшелчә 60—100 центнердан артмый. Трампарк, Куйбышев исемендәге фабрика, «Спартак» комбинаты, киез итек-фетр фабрикасы, 4 нче номерлы ясалма каучук заводы һ. б. узган елны бигрәк тә түбән уңыш алдылар. Шуның өстенә, чәчү планнары да узган елны үтәлмичә калды.

Ярдәмче хуҗалыклардагы җитешсезлекләрнең, уңышның түбән булуының төп сәбәпләреннән берсе—кыр эшләренә узган елны соңга калып әзерләнү һәм үткәрү, шулай ук парник-теплица хуҗалыгына тиешенчә бәя биреп җиткермәү булды. Мәсәлән, партоешма секретаре урынбасары Ставер булган завод, 4 нче ясалма каучук заводы, Куйбышев исемендәге фабрика һ. б. үзләрендә булган парник хуҗалыкларыннан бер генә килограмм да яшелчә ала алмадылар. Быел ярдәмче хуҗалыкларда парник-теплица эшләренә карашны тамырыннан үзгәртергә, алардан җитәрлек күләмдә иртә өлгерә торган яшелчәләр алуга, үз ихтыяҗларын һәм шулай ук индивидуаль түтәлчелек ихтыяҗларын да капларлык рассада булдыруга ирешергә кирәк.

Терлекчелек өлкәсендә дә эшләр һич тә канәгатьләнерлек алып барылмый. Терлекчелекне үстерү эшләрен (бигрәк тә дуңгыз һәм йорт кошлары буенча) начар оештыру нәтиҗәсендә, терлекләр санын һәм аларның продуктлылыгын арттыру планы үтәлми («Спартак» комбинаты, партоешма секретаре урынбасары Ставер булган завод һ. б.). Җитәрлек кадәр терлек азыгы базасы булдыру буенча да тиешле эш алып барылмый. Тегү фабрикалары, җитен комбинаты, Искож, Энергокомбинат, ясалма каучук заводы һ. б. кебек предприятиеләр хуҗалыкларында терлекләр әле һаман да бөтенләй юк.

Бу барлык җитди кимчелекләр—ярдәмче хуҗалыклардагы җитәкчеләрнең эшлексез, инициативасыз булуларыннан, тапшырылган гаять зур политик эшкә җавапсыз карауларыннан, большевистик практик эшне мәгънәсез лыгырдау белән алмаштыруларыннан килә.

Хәзер безнең сугышчан бурыч—үткән елдагы ялгышлыклардан сабак алып, моннан соң инде аларны кабатламаудан, быелгы язгы чәчүгә отлично әзерләнеп, аны үрнәк төстә үткәрүдән, ярдәмче хуҗалыклардан югары хәрби уңыш алуга ирешүдән гыйбарәт. Чәчү планын һәм һәрбер культура буенча билгеләнгән күләмдә уңыш алу планын, шулай ук кышкы агротехника чараларын тулысынча һәм төгәл итеп үтәүгә барлык көч мобилизацияләнергә тиеш. Хәзер үк инде барлык ярдәмче хуҗалыкларда бәрәңге, яшелчә һәм башка орлыкларны тулысынча әзерләп куярга кирәк. Бәрәңге орлыгы өчен, аеруча, бәрәңге күзәнәге кисентесе әзерләү планы, һичбер сүзсез, үтәлергә тиеш. 1943 нче елда барлык ярдәмче хуҗалыкларда үзләренең кәбестә һәм помидор рассадалары булдыруга, иртә өлгерә торган яшелчәләр җитештерүне күп тапкыр үстерүгә ирешергә кирәк.

Эчке ресурсларны максимум рәвештә мобилизацияләргә кирәклек турында бик күп күрсәтмәләр булуга да карамастан, кайбер ярдәмче хуҗалыкларның, Орсларның, предприятиеләрнең җитәкчеләре югары оешмалардан орлык, фураж, машина, инвентарь, пыяла, тимер һ. б. җибәрелүен сорыйлар. Ватан сугышы шартларында мондый зарарлы иждивенчелек настроениеләренә чик куелырга тиеш. Хәзерге шартларда дәүләттән азрак алырга, үзең күбрәк эшләргә кирәк.

Югары уңыш алуда җиргә төрле ашламалар кертү чаралары хәлиткеч зур роль уйный. Ләкин, әйтергә кирәк, ашламалар әзерләү, кырга тирес ташу, кар тоту кебек эшләр күпчелек ярдәмче хуҗалыкларда әле һаман да бик начар алып барыла: Мәсәлән, Жиромбинат, тегү фабрикалары, Трампарк һ. б. үзләренең ярдәмче хуҗалык кырларына әлегә кадәр бер генә тонна да тирес чыгармаганнар.

Тракторлар паркын, авыл хуҗалыгы машиналарын һәм инвентарен тулы әзерлек хәленә китерергә кирәк. Хуҗалыкларда һәм предприятиеләрдә барлык ремонт материалларын тулысынча файдалану—үз машиналарын һәм инвентарен ремонтлауны гына түгел, бәлки бу эштә күрше колхозларга ярдәм күрсәтүне дә тәэмин итәргә тиеш иде. Ләкин чынлыкта исә эш башкача тора. Партоешма секретаре урынбасары Ставер булган заводта 15 трактордан нибары 5 трактор гына, төзү трестында — 19 трактордан 7 трактор гына ремонтланган әле һ. б. Ремонт эшләрен бүгенге көнгә кадәр хәтта әле бөтенләй башламаган хуҗалыклар да юк түгел. Димәк, трактор һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясау эшләре хәзер иң сугышчан бурычларның берсе булып каралырга тиеш. Бу эшне 15 нче мартка кадәр тәмам төгәлләргә кирәк. Шулай ук, промышленность отходларыннан кул инвентаре—тырмалар, көрәкләр, китмәннәр һ. б. әзерләү эшләренә дә хәзер үк керешергә кирәк.

Татарстандагы промышленность предприятиеләре һәм башка оешмалар каршындагы ярдәмче хуҗалыкларда 1944 нче елның 1 нче январена дуңгызлар саны 21.468 башка, эре мөгезле терлекләр саны —8.983 башка, сарыклар саны—7.460 башка, йорт кошлары саны—20.950 башка, умарта—2.881 семьяга, бер фуражлы сыердан сөт савып алу—1,5—2 мең литрга җиткерелергә тиеш. Әгәр дә ярдәмче хуҗалык работниклары, терлекчелек эше белән ватан интереслары таләп иткәнчә җитди рәвештә шөгыльләнсәләр, бу минималь план, һичшиксез, үтәлер.

Югары уңыш алу өчен көрәш кыштан ук башлана. Бер генә көнне дә, бер генә сәгатьне дә әрәм итмәскә, алга куелган бурычларның отлично үтәлүе өчен һәрбер минутны нәтиҗәле итеп файдаланырга кирәк. Ярдәмче хуҗалыкларда нык тәртип, оешканлык, тимердәй хезмәт дисциплинасы урнаштырылырга, социалистик ярыш киң җәелдерелергә тиеш. Безнең республикабызда бер генә дә артта калучы ярдәмче хуҗалык булмасын. 1943 нче ел—барлык ярдәмче хуҗалыкларда югары хәрби уңыш алу елы булсын!

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ОТЛИЧНО ӘЗЕРЛӘНИК!

„ПАРТИЗАН" КОЛХОЗЫНДА

— Моннан өч ай элек һөҗүмгә күчкән данлыклы Кызыл Армия бер-бер артлы уннарча шәһәрләрне һәм йөзләрчә авылларны дошманнан чистартты. Радио безгә тагын шатлыклы хәбәр китерде. Ростов, Ворошиловград һәм Харьков яңадан безнеке! Алар өстендә тагын горурлык белән совет кызыл байрагы җилферди.

Ораторның бу сүзләренә колхозчылар шатлыклы кул чабулар белән җавап бирделәр.

Ростов, Ворошиловград һәм Харьков шәһәрләре оккупантлардан азат ителү уңае белән Шөгер районының «Партизан» колхозында җыелган митинг әнә шулай башланды.

«Партизан» колхозы барлык политик һәм хуҗалык кампанияләре буенча районда алдынгы урында бара. Дәүләт йөкләмәләрен срогыннан алда үтәп килә. Колхоз 1943 нче ел өчен дә дәүләткә ит тапшыру йөкләмәсен күптән үтәде инде. Колхозда язгы кыр эшләренә әзерлек уңышлы бара.

Митингта чыгарылган резолюцияләрендә колхозчылар болай дип яздылар:

— Ростов, Ворошиловград һәм Харьков шәһәрләренең азат ителүе турындагы хәбәр безне тагын да зуррак уңышларга рухландыра. Без язгы чәчүгә әзерлекне Кызыл Армиянең 25 еллыгына — 23 нче февральгә үрнәк булырлык итеп төгәлләргә, язгы кыр эшләрен кыска срокта, яхшы сыйфатлы итеп үтәп чыгарга сүз бирәбез.

Колхозчылар, Кызыл Армиябезнең уңышлы хәрәкәтләренә җавап итеп, Кызыл Армия фондына 500 килограмм ит бирү турында да карар кабул иттеләр.

М. ХӘМИДУЛЛИН.

АГРОТЕХНИКА ЧАРАЛАРЫ АРТТЫРЫП ҮТӘЛӘ

БИЕКТАУ, 17 февраль. (Телефон буенча). Кызыл Армиябезнең Харьковны алуы турындагы хәбәр районның барлык совхозларына һәм колхозларына яшен тизлеге белән таралды.

Хәзер барлык колхозларда да бу уңай белән митинглар бара. Бу митинглар, аларда катнашучыларның күплеге һәм активлыгы белән, моннан элек үткән митинглардан аерылып тора.

«Бирюли» совхозында, «Смычка», «Победа» һәм «Искра» колхозларындагы митинглар да нәкъ әнә шулай үтте.

«Искра» колхозы Харьков шәһәренең алынуын язгы чәчүгә тулысынча әзер булу белән каршылады. Колхозчылар Кызыл Армиябезнең бу яңа уңышына язгы чәчүгә әзерлекне тагын да яхшырту, югары иген уңышы өчен көрәшне тагын да көчәйтү белән җавап кайтарырга карар бирделәр. Митингтан соң ук язгы чәчүгә әзерлекнең барлык тармакларында эш яңадан кызды. Бу колхоз кышкы агротехника чаралары планын күптән төгәлләгән иде инде. Хәзер биредә кар тоту, басуга тирес чыгару, җирле ашламалар туплау кебек эшләр планнан тыш алып барыла.

Д. СКВОРЦОВ.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Танк десанты һөҗүм итә.
ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

17 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

17 нче февральдә Украинада безнең гаскәрләр каты сугышлар нәтиҗәсендә, **Славянск** шәһәрен һәм тимер юл узелын, шулай ук **Ровеньки**, **Свердловск**, **Богодухов**, **Змиев** шәһәрләрен, район үзәкләреннән **Алексеевскоены** һәм **Славяносербскины** алдылар.

Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, **Грайворон** шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм немецларның туздырылган частьларының калдыкларына ударлар ясадылар. Н-че берләшмә сугышчылары сугышларның өч көне эчендә немецларның 70 танкысын, 11 самоход орудиесен, күп кенә транспортерларын һәм автомашиналарын юк итте. Безнең бер частебызның сугышчылары бер самолет, 9 танк, 16 аэрочана һәм берничә дистә автомашина кулга төшерделәр. Гитлерчыларның чигенү юллары үз солдатларының һәм офицерларының үле гәүдәләре белән, шулай ук немецлар ташлап калдырган авыр һәм җиңел кораллар белән тулды.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар. Дошман бик каты каршылык күрсәттә, ләкин сугышлар һәрвакытта да безнең гаскәрләрнең җиңүе белән тәмам булалар. Н-че берләшмә частьлары, алга таба барып, халык яши торган 11 пунктны алдылар һәм 2.000 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Күп пленныйлар алынды. 23 танк, 18 орудие, шулардан 2 самоход орудие, 30 пулемет, 28 миномет һәм 5 бронемашина юк ителде. 12 орудие, 2 танк, 46 пулемет, 28 автомашина 1 штаб автобусы һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Краматорская районында безнең сугышчылар дошман мотопехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар нәтиҗәсендә бер батальоннан артык гитлерчыларны кырдылар һәм халык яши торган 3 зур пунктны алдылар. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта безнең гвардеецлар дошманның 78 самолетын 17 моторын, 29 орудиесен, 1.300 винтовкасын, 50.000 патронын, 8 складын һәм ашлык тутырылган 2 элеваторын кулга төшерделәр.

* * *

Грайворон районында безнең гаскәрләр алга киттеләр. Аеруча каты сугышлар халык яши торган бер зур пункт өчен булды. Монда дошман берничә тапкыр контратакаларга күчте. Безнең сугышчылар гитлерчыларны хәлсезләндерделәр, ә соңыннан кискен атака ясап, немецларны бу терәк пункттан бәреп чыгардылар. 400 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды.

Фатеждан көнбатыштарак безнең гаскәрләр, су чиге аркылы үтеп чыгып, халык яши торган бер зур пунктка бәреп кerделәр һәм каты сугышлардан соң аны алдылар. Немецларның 8 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Ике ротадан артык гитлерчылар кырып ташланды.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Безнең частьларның ударлары астында дошман гаскәрләре үзләре өчен зур югалтулар белән чигенәләр. Бер участокта гына да ике көн эчендә 1.000 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары кырып ташланды. Төрле калибрдагы 10 орудие, сугыш припаслары һәм башка сугыш милекләре тутырылган 2 склад кулга төшерелде.

* * *

Ростов өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче «За тихий Дон» отряды партизаннары немец-фашист басып алучыларны тар-мар итүдә Кызыл Армиянең һөҗүм итеп килүче частьларына актив булышлык итәләр. Партизаннар, яшерен юллар белән, безнең ике пехота батальонын дошман флангысына алып чыктылар. Кызылармеецлар, немецларга кинәт атака ясап партизаннар белән бергәләп, халык яши торган һәм зур әһәмияте булган 2 пунктны алдылар. Икенче бер отрядның партизаннары дошманның туздырылган һәм чигенеп бара торган группаларына каршы сугыш алып барганнар һәм 90 гитлерчыны юк иткәннәр.

* * *

Германия информация бюросы түбәндәге хәбәрне тапшыра: «Ворошиловград районында совет группировкасын моннан элек башланган чолгап алу тулысынча тәгәлләнде. Аларны чолгап алган Германия танк көчләре бу группировканы юк итә башладылар». Гитлерчыларның бу хәбәре башыннан ахырынача ялган: Совет гаскәрләре, Ворошиловградны алганнан соң, немец-фашист гаскәрләрнең туздырылган частьларын куып баруларында дәвам итәләр. Фронт инде шәһәрдән еракка күчте. Немец гаскәрләре чигенәләр һәм бик күп кешеләрен һәм техникаларын югалталар. Кая инде аларга бу районда совет гаскәрләрен чолгап алырга. Немец-фашист гаскәрләренең булмаган уңышлары турында гитлерчыларның ялган әкиятләр уйлап чыгарулары очраклы хәл түгел. Монды жуликлык алымнары белән алар совет-немец фронтында немец гаскәрләренең бик күп зур җиңелүләре турындагы хәбәрләр нәтиҗәсендә Германиядә туган авыр тәэсирне йомшартырга маташалар.

ХӘРБИ ЗАЕМГА ЯЗЫЛУЧЫЛАРГА ОБЛИГАЦИЯЛӘР ӨЛӘШҮ

1942 нче елгы Дәүләт хәрби заемына язылу буенча взнослар түләнеп беткәнлектән предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм колхозларда заемга язылучыларга облигацияләр өләшелә башланды.

СССР Финанс халык комиссариаты билгеләнгән тәртип буенча һәрбер предприятиенең һәм учреждениенең бухгалтериясе, финанс агентлары һәм авыл советлары уполномоченныйлары облигацияләр өләшүне шушы елның 1 нче мартына кадәр тәмам итәргә тиешләр. Тапшырылмаган облигацияләр барысы да саклык кассаларына кире җибәреләләр. Облигацияләрне саклык кассаларыннан алу өчен бер ел срок билгеләнде.

Хәрби заемның беренче отышлар тиражы 1943 нче елның 26 нчы маенда үткәреләчәк.

АНГЛИЯ һӘМ АМЕРИКА АВИАЦИЯСЕНЕҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 16 февраль. (ТАСС). Англия авиация министрлыгының һәм Американың Европадагы кораллы көчләре штабының белдерүендә әйтелүенчә, 15 нче февральдә Англия һәм Америка самолетлары Дюнкеркка һәм андагы пароходларга һөҗүм иткәннәр. Беренче һөҗүмне Англия бомбардировщиклары, ә шуннан соң ике сәгать үткәч башланган икенче һөҗүмне Америка бомбардировщиклары ясаган. Һаваның аяз булуы бомбага тотуның нәтиҗәләре яхшы булганлыкны күрергә мөмкинлек биргән.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 15 нче февральгә каршы төндә Миланга һөҗүм иткән Англия бомбардировщиклары шул ук вакытта итальяннарның Генуядан 50 миль чамасы көньяк-көнчыгыштарак урнашкан хәрби диңгез базасы Специягә дә бомбалар ташлаганнар. Специядә пароходлар ясау верфьләре, шулай ук су асты көймәләре генә ясый торган махсус верфьләр бар.

Англия бомбардировщикларының Миланга ясаган һөҗүме нәтиҗәсендә бөтен район ут белән чолгап алынган. Янгынны 150 миль ераклыктан күрергә мөмкин булган. Зенит артиллериясенең уты бик көчле булмаган.

* * *

ЛОНДОН, 16 февраль. (ТАСС). Англиянең Якын көнчыгыштагы кораллы көчләре командованиесенең белдерүендә әйтелүенчә, 15 нче февральдә Англия гаскәрләре Бен Гарданны алганнар һәм хәзер бу шәһәрдән көнбатыштарак дошманга каршы сугышлар алып баралар. Сугышлар районы турысында авиациянең хәрәкәтләре истребительләрнең активлыгы белән чикләнгән.

15 нче февральгә каршы төндә Англия самолетлары түбәннән генә очып, Сицилия атавындагы һәм Италиянең көньяк өлешендәге объектларын бомбага тотканнар.

Америка бомбардировщиклары Неапольгә һөҗүм иткәннәр.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 15 нче февральдә Тунис фронтының көньяк секторында Америка гаскәрләре, немецларның диңгез ярыннан 110 миль ераклыктагы Гафса юнәлешендә көчле яңа басымнарын тоткарларга тырышып, бик каты сугышлар алып барганнар. Немецлар Америка позицияләренә 20 миль чамасы эчкәре кергәннәр һәм кичкә таба Гафсаны алганнар. Американың бронетанк частьлары контратакалар ясап, бик каты сугышлардан соң, һөҗүм итүче Германия гаскәрләрен 6 мильгә артка таба алып ташлаганнар.

Югославиядә партизаннар көрәше

ҖЕНЕВА, 16 февраль. (ТАСС). Югославиядән алынган хәбәрләргә караганда, азат ителгән территориядәге партизаннар һәм халык һәрьяктан һөҗүм итеп килүче оккупантлар гаскәрләренә бик каты каршылык күрсәтүләрен дәвам иттерәләр. Аеруча көчле сугышлар Баня-Лукадан көнбатыштарак һәм көньяк-көнбатыштарак Сански мост районында бара.

Баня-Лукадан көньяктарак Бугойно районында партизаннар усташиларның зур бер отрядын тар-мар иткәннәр. Сугыш кырында дошман солдатларының һәм офицерларының 200 дән артык үле гәүдәләре калган.

Загребтан көньяктарак Бихач шәһәре янында бик каты сугышлар булган. Партизаннар күп көннәр буена каршылык күрсәткәннәр. Дошманның бик күп кешеләре һәм техникасы югалган. Ләкин дошманның шактый өстен көчләренең басымы астында партизаннар Бихач шәһәрен калдырып чыгарга мәҗбүр булганнар. Сугышлар шәһәрдән читтә дәвам итә.

РУМЫНИЯДӘ ЧИМАЛ ЗАПАСЛАРЫ КИМИ

ИСТАМБУЛ, 16 февраль. (ТАСС). Румыниядәге чимал запасларының күп өлеше Германия промышленностена китә. Хәзер аның чимал запаслары һәлакәтле төстә тизлек белән бетеп бара. Швейцариядә чыга торган «Нейе Цюрхер цейтунг» газетасы хәбәрчесенең Бухарестган язуына караганда, Румыниянең үз промышленностен чимал белән тәэмин итүдәге кыенлыклары торган саен үсә бара. Барыннан да бигрәк чималның металлургия һәм машина төзелешендә бик нык җитешмәве күренә. Румыннар чималга булган ихтыяҗны оккупацияләнгән совет районнарын талау юлы белән капларга тырышалар. Румын талаучылар аннан бөтен металлны чыгарып бетергәннәр. Халыкның металлдан ясалган барлык әйберләре, шул исәптән савыт-сабалары да талап алынган. Румыния властьлары бакыр акчаларны күптән инде әйләнештән алганнар һәм алар урынына цинк акчалар йөртә башлаганнар.

«Порунка времий» газетасы, сугыш припаслары промышленносте өчен чимал җитешмәү бик кискенләште, дип икърар итә.

Германия матбугатының бик саран гына бирелә торган хәбәрләренә караганда, Румыния промышленностеның башка тармакларында да чимал мәсьәләсе шулай ук начар тора. Армия киемнәре өчен материал әзерләүче текстиль предприятиеләренең күбесе чимал булмаганлыктан ябылыр алдында торалар. «Донау цейтунг» һәм «Дейче цейтунг ин кроатиен» газеталарының язуына караганда, күптән түгел Румыниянең хәрби министрлыгы бу предприятиеләр өчен илдә булган барлык мамык сүсе запасларына реквизияция ясаган.

РЮТИ ЯҢАДАН ФИНЛЯНДИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ИТЕП „САЙЛАНГАН“

СТОКҺОЛЬМ 16 февраль. (ТАСС). Рютиның Финляндия президенты итеп «яңадан сайланганлыгы» Хельсинкида рәсми рәвештә игълан ителгән. Финляндия конституциясе буенча сайлаулар ике тапкыр тавышка куелу юлы белән үткәрелергә тиеш иде. Башта 300 сайлаучы сайланырга, ә соңыннан алар президентны сайларга тиешләр иде. Ләкин бу юлы бернинди дә сайлаучылар сайланмаган. Рютины 1937 нче елны президент сайлаган чакта сайлап куелган 300 сайлаучы җыелышында «яңадан сайлаганнар». Шуның белән бергә Рютины яклап 269 тавыш бирелгән. Мәгълүм ки, шул ук сайлаучылар 1940 нчы елны да президент итеп Рютины сайлаганнар иде. Стокһольмдагы журналистларның әйтүенчә, шулай итеп Финляндиядә президент сайлау баштанаяк ялган сайлау булып чыккан.

ИРАН ХӨКҮМӘТЕНЕҢ АЛМАШЫНУЫ

ТАҺРАН, 15 февраль. (ТАСС). Иранның министрлар советы председателе Әхмәд Гавам отставкага чыккан. Шаһ яңа кабинет төзүне Сөхәйлигә тапшырган. Сөхәйлинең кандидатурасын мәҗлес тавышлар күпчелеге белән раслаган.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

«Кызыл Татарстан» коллективы редакциясенең үз хәбәрчесе Бари иптәш **Латыйповның** 17 нче февральдә вакытсыз үлүе турында тирән кайгы белдерә һәм семьясының кайгысын уртаклаша.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген—„*Мәрьям*“. 19 нчы февральдә „*Хуҗа Насретдин*“.

Зур драма театры. Бүген—„*Фронт*“. 19 нчы февральдә—„*Маскарад*“.

Дәүләт циркы. Бүген—зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — „*Музыкаль вакыйга*“.

„Унион“—көндез—„*Партбилет*“, кич—„*Котовский*“.

„Пионер“—көндез һәм кич—„*Алтын кул*“.

„Чатқы“—„*Зур вальс*“.

„Кызыл йолдыз“—„*Укытучы*“.

ПФ646 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 263